# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советы

Илбәк авылы №114 «27»декабрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 11 ноябрендәге 106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (18.08.2015 елның 130 номерлы, 29.10.2015 елның 13 номерлы, 24.04.2018 елның 87 номерлы, 15.11.2018 елның 109 номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 11 ноябрендәге 106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (18.08.2015 елның 130 номерлы, 29.10.2015 елның 13 номерлы, 24.04.2018 елның 87 номерлы, 15.11.2018 елның 109 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2. пунктлар өстәргә:

«3.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балаларын.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын

бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган салым түләүче тарафыннан салым органына тапшырыла торган салым салу объектлары турында хәбәрнамә үзенең теләге белән елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торган салым органына тапшырыла, аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла.

Салым органына сайлап алынган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырган салым чоры булып торган елның 1 ноябреннән соң салым салу объекты үзгәртелеп, күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы тапшырыла торган төгәлләштерелгән белдерү кәгазе тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче сайлап алынган салым ташламасы салым салу объекты турында хәбәрнамәне тапшырмаган очракта салым ташламасы һәр төр салым салуның иң чик исәпләнгән суммасы белән бер объектына карата тапшырыла.»

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 109 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 11 ноябрендәге 106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (18.08.2015 елның 130 номерлы, 29.10.2015 елның 13 номерлы, 24.04.2018 елның 87 номерлы карарлар редакциясендә) карарында»:

икенче пункттагы «һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар үз көченә “Маяк” газетасында рәсми бысылып чыккан көннән соң бер ай узгач үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatarstan.ru.веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, Финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина

РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЕВСКИЙ ТАТАРСТАН
ИЛБӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИЛЬБЯКОВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ